ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАТАР СУКСУЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

423736, Татар Суксуы авылы,
Гагарин ур.,1 б нче йорт.
Тел. 3-44-60

e-mail: tsuk-akt@yandex.ru

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ТАТАРСКО-СУКСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423736, с. Татарские Суксы,
ул. Гагарина, дом 1 б.
Тел. 3-44-60
e-mail: tsuk-akt@yandex.ru

---

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**30 ноябрь 2020 ел** **№11**

**Татар Суксуы авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында**

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25,1,56 статьялары, 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татар Суксуы авыл җирлеге Советы гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә карар кабул итте:

1. Татар Суксуы авыл җирлеге территориясендә 2021 елда, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, көндезге формада белем алучы студентлар, 1 төркем инвалидлар һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү өчен, Татар Суксуы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләүләр кертергә:

- су челтәрләрен ремонтлау, карап тоту, су белән тәэмин итү чыганакларын ремонтлау һәм лицензияләү;
- күмү урыннарын ремонтлау һәм карап тоту;
- санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү;
- чишмәләрне төзекләндерү;
- Сабантуй үткәрү урыннарын төзекләндерү;
- рәсми физкультура-сәламәтләндерү, спорт чараларын оештыру һәм уздыру;
- авыл җирлеге территориясендә, зират территориясендә агач кисү;
- җирләү урыннарын документаль рәсмиләштерү;
- юлларны ремонтлау һәм карап тоту (ПГС салу, ЩПС салу, грейдерлау, кардан чистарту);
- хуҗасыз территорияләрне ремонтлау һәм коймалау;
- урам исемнәре, йорт номерлары язылган күрсәткечләр урнаштыру;
- Бөек Ватан сугышында катнашучыларның обелискларын урнаштыру һәм ремонтлау;
- игълан стендларын ясату;
- балалар спорт-уен комплексы сатып алу;

- урамнарны яктырту электр челтәрләрен карап тоту һәм ремонтлау;
- хуҗасыз объектларны сүтү;
- ГТСны декларация алды тикшерүе үткәрү.

2. Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлеге гражданнарының авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында җыелу нәтиҗәләрен игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында Татар Суксуы авыл җирлеге " бүлегендә урнаштырырга.».

Татар Суксуы Авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Хамматуллина